| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА АЗНАКАЕВО<br>АЗНАКАЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330 | Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330 |

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 ел № 16

Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен урыннар билгеләү хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, 2018 елның 27 декабрендәге 498 – ФЗ номерлы «Хайваннарга карата мөнәсәбәтнең җаваплылыгы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 8 статьясы, 2009 елның 27 декабрендәге 120 номерлы «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 июлендәге 494 номерлы «Тиешле территориядә теркәлгән этләр санынннан чыгып, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә этләрне урамда йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын билгеләүнең тәкъдим ителә торган критерийларын раслау турында» карары, Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай шәһәр Советының 2006 елның 19 маендагы 28-6 номерлы карары белән расланган Азнакай шәһәрендә чисталык һәм тәртипне саклау һәм тышкы төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен чикләр белән рөхсәт ителгән урыннарны билгеләргә:

- Тарсус паркындагы мәйданчык (паркның көнчыгыш өлеше - координатлары 54,8570*53,0606);
- Мәнәвез микрорайонына кергәндә урнашкан мәйданычык (тротуар ягыннан - 54,8688*53,0475);
- Мәнәвез микрорайонда мәйданчык (балалар мәйданчыгы территориясе артында – 54,8625*53,0261).

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнашытырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.И. Солтанов